КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 3 июль г.Казань № 538

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2020 ел, 8 декабрь, 1105 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучының күчерү буенча вәкаләтләрен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр 2021 елда аларның кабул ителгән карарлары нигезендә Федераль казначылык Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тапшыра торган, максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган бюджетара трансфертлар исемлегенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2020 ел, 8 декабрь, 1105 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучының күчерү буенча вәкаләтләрен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш

итүчеләр 2021 елда аларның кабул ителгән карарлары нигезендә Федераль казначылык Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тапшыра торган, максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган бюджетара трансфертлар исемлегенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

түбәндәге юлдан соң:

| | |
|---|---|
| «Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата бүләкләүне түләүне гамәлгә ашыру өлешендә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү өчен бюджетларга субвенцияләр | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы» |

түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| «2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрүгә субвенцияләр | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин